

Темников районы Зур Татар Карай – Большое Татарское Караево авылында яшәvчеләр артезиан скважинасын бергәләп ремонтладылар.
Артезиан скважиналары ярдәмендә авыл жирлекләрендә яшәvчеләрне су белән тәэмин ителәә, кvптән тозелгән; павильоннарын да даими ремонтларга туры килә. Зур Татар Карай авылында яшәvчеләр алдында да ремонт мәсьәләсе кvтәрелгән.      Уноч ел дәвамында насос эшен кvзәткән Нәбиулла Поздняков аркасында су, ин кочле салкыннарда да, тунмаган. Ә кvптән тvгел, Зур Татар Карай авылы активистлары инициативасы белән, яраксызга килгән бинанын тvбәсен ремонтлау турында Карар кабул итеалә.
Кирәкле материалларны авыл халкы vзләре әзерләгән. Ә якшәмбе конне, барысы да жыелылышып, бина тvбәсен алыштырганнар, эчке жиһазларны янарт-каннар. Хәзер автоматика ярдәмендә Зур Татар Карае авылында яшәvчеләргә озлексез су бирv тәэмин ителгән. Менә, чыннан да, бергә жыелып башланган эш, бергә эшләv - алга китеш, бергә эшләv - зур уныш.